ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                  КАРАР

11.11.2025 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 03

пос. Октябрьский

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 27 ноябренә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы гражданнары үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: «Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

   - Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Ключищи авылы зираты территориясен төзекләндерү):

   «ӘЙЕ»                              «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Ключищи авылы, Колхоз урамы, 95 адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында 10.00 сәгатьтә уздырырга.
4. Октябрьский авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш.Р. Азизов